СОВЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**
**11.04.2016**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 80**

2014 елның 05 ноябрендәге 459 номерлы «Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссияләре турында нигезләмәне раслау хакында» Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында (2015 елның 10 июлендәге 545 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карары белән кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләр белән)

2014 елның 22 декабрендәге 431-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, 2015 елның 23 мартындагы УП-308 номерлы «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Указын, 2016 елның 18 мартындагы ПУ-265 «Татарстан Республикасының аерым дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксынулары барлыкка килү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Президентының Указын исәпкә алып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1. Зеленодольск муниципаль район Советының 2014 елның 05 ноябрендәге 459 номерлы карары белән расланган "Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр хакындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссияләр турында нигезләмәгә (2015 елның 10 июлендәге 545 номерлы Зеленодольск

муниципаль районы Советы карары белән кертелгән өстәмәләр һәм үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 пунктның «б» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерә ала торган шәхси кызыксыну барлыкка килү турында муниципаль хезмәткәрнең хәбәр итүе;»;

2) 15.1 пунктыннан дүртенче җөмләне төшереп калдырырга;

3) 15.3 пунктыннан икенче җөмләне төшереп калдырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле 15.4. һәм 15.5 пунктлар өстәргә:

«15.4. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамә, җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча кадрлар хезмәте бүлекчәсе яисә җирле үзидарә органының коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан карала, ул хәбәрнамәне карау нәтиҗәләре буенча мотивлаштырылган бәяләмә әзерли.

15.5. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының икенче абзацында күрсәтелгән мөрәҗәгатьне карау нәтиҗәләре буенча яисә әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында һәм «д» пунктчасында күрсәтелгән хәбәрнамәләр, җирле үзидарә органының кадрлар бүлекчәсенең вазыйфаи затлары мөрәҗәгатьне яисә хәбәрнамәне тапшырган муниципаль хезмәткәр белән әңгәмә уздырырга, аннан язма аңлатмалар алырга хокуклы, ә җирле үзидарә органы җитәкчесе яисә аның урынбасары, махсус шуңа вәкаләтле вәкилгә, билгеләнгән тәртиптә дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга рәсми мөрәҗәгать җибәрергә мөмкин. Мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар килгән көннән алып җиде эш көне эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Рәсми мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә, шулай ук бәяләмә һәм башка материаллар юлланган очракта, мөрәҗәгать яисә хәбәрнамә кергән көннән алып 45 көн эчендә комиссия рәисенә тапшырыла. Күрсәтелгән вакыт озайтылырга мөмкин, әмма 30 көннән дә артык түгел.»

5) 16 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) 10 көн эчендә комиссия утырышы датасын билгели. Бу чакта комиссия утырышы датасы әлеге мәгълүмат кергән көннән 20 көннән дә соңга калмыйча билгеләнә алмый, әлеге Нигезләмәнең 16.1 һәм 16.2 пунктларында каралган очраклардан тыш;»;

6) 16.1 пунктында «өченче абзацта күрсәтелгән гаризалар» сүзләрен «өченче һәм дүртенче абзацларда күрсәтелгән гаризалар» сүзләренә алмаштырырга;

7) 17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Комиссия утырышы, кагыйдә буларак, муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне һәм (яки) мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу таләпләрен үтәү турында мәсьәлә карала торган муниципаль хезмәткәр катнашында яисә муниципаль хезмәт вазыйфасы биләүче граждан барында җирле үзидарә органында үткәрелә. Муниципаль хезмәткәр яисә граждан комиссия утырышында шәхсән катнашырга теләге турында әлеге Нигезләмәнең

14 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә тапшырыла торган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә күрсәтә.»;

8) түбәндәге эчтәлекле 17.1 пункт өстәргә:

«17.1. Комиссия утырышлары муниципаль хезмәткәр яисә граждан булмаганда түбәндәге очракларда үткәрелергә мөмкин:

а) әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасында каралган мөрәҗәгатьтә, гаризада яисә хәбәрнамәдә муниципаль хезмәткәрнең яисә гражданның комиссия утырышында шәхсән катнашырга ниятләве турында күрсәтмә булмаса;

б) әгәр муниципаль хезмәткәр яисә граждан комиссия утырышында шәхсән үзе катнашырга ниятләүче һәм аны үткәрү вакыты һәм урыны турында тиешле рәвештә хәбәр ителгән булса, комиссия утырышына килмәделәр.»;

9) 23.3 пункт өстәргә.

«23.3. Әлеге Нигезләмәнең 14 пунктындагы «б» пунктчасының бишенче абзацында күрсәтелгән мәсьәләне карау йомгаклары буенча комиссия түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликты булмавын танырга;

б) муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр конфликтына китерә яисә китерә алуын танырга. Бу очракта комиссия муниципаль хезмәткәргә һәм (яисә) җирле үзидарә органы җитәкчесенә мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу яисә аның барлыкка килүен булдырмау чараларын күрергә тәкъдим итә;

в) муниципаль хезмәткәр мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу турындагы таләпләрне үтәмәде дип танырга. Бу очракта комиссия җирле үзидарә органы җитәкчесенә муниципаль хезмәткәргә карата җаваплылыкның конкрет чарасын кулланырга киңәш итә.»;

10) 24 пунктта «20 - 23, 23.1, 23.2 һәм» сүзләрен «20 - 23, 23.1 - 23.3 пунктлары һәм» сүзләренә алмаштырырга;

11) 31 пунктта «3 көнлек вакыт» сүзләрен «7 көнлек вакыт» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**